Әхмәтшина Айгөл Фаукат кызы
1нче квалификацион категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы
«Адымнар-Алабуга» күптелле белем бирү комплексы

# РИЗА ФӘХРЕДДИН ИҖАТЫН ТӘРБИЯ ПРОЦЕССЫНДА КУЛЛАНУ

Риза Фәхреддинов – киңкырлы эшчәнлек алып барган энциклопедик галим. Ул тарих, педагогика, тел белеме, әдәбият, фәлсәфә, сәнгать, география, этнология, генеалогия, эпитафия, медицина, нумизматика, юриспруденция, халык авыз иҗаты, дин тарихы кебек фәннәр белән тирәнтен кызыксына, алар буенча саллы хезмәтләр яза. Билгеле булганча, Р.Фәхреддинов XIX йөзнең икенче яртысында, ягъни татар дөньясында мәгърифәтчелек карашлары иң киң колач җәйгән вакытта иҗат итә.

Р.Фәхреддин иҗаты, эшчәнлегенә игътибар итү аны чын мәгънәсендә әхлак гыйлеменең теоретик нигезләрен барлыкка китерүче дип аталырга лаеклы булуын күрсәтә. Ул гомере буе балаларга да, ата-аналарга да тәрбия бирүгә, мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укытуга кагылышлы мәсьәләләрне уңай хәл итәргә, тәрбияви эчтәлекле хезмәтләр, дәреслекләр, кулланма-ярдәмлекләр тудыруга хәленнән килгәнчә ярдәм итә. Аның педагогика мәсьәләләренә кагылышлы китапларының саны җитмеш җидегә җитә.

Вакытлар узу белән, Р.Фәхреддинов әсәрләре һәм хезмәтләренең әһәмияте һич тә кимимичә, киресенчә, арта гына. Хәзерге тормышта әхлакый тәрбиягә җитди игътибар бирергә кирәк. Бу җәһәттән Р.Фәхреддин хезмәтләре аеруча игътибарга лаек.

Галимнең хезмәтләрендә әхлак тәрбиясе даими рәвештә гаиләдә ата-аналар тарафыннан, мәктәп-мәдрәсәләрдә мөгаллимнәр тарафыннан, әйләнә-тирәлектә күршеләр, туганнар тарафыннан гамәлгә ашырылырга тиеш, дигән фикер үткәрелә. Шулай да Р.Фәхреддин фикеренчә, тәрбиянең иң беренче һәм мөһим чыганагы – гаилә, ата-ана. Р.Фәхреддинов балаларны әти-әниләргә карата ихтирамлы, итагатьле булырга чакыра. “Әхлак гыйлеме”нең

“Балалар өчен” дигән бүлегенең беренче битендә үк автор “Кешенең итагатьле (буйсынучан) булуы – күңеле яхшы булу галәмәтедер. Инде сезгә иң якын кешеләр дә, әлбәттә, ата вә аналарыгыздыр. Шуның өчен аларга һәрвакытта да итагатьле булыгыз, гамәл вә сүздә аларга каршы килмәгез, бу сәбәптән аларның күңелләре дә рәхәтләнер, үз күңелләрегез дә вә дөньяда торугыз да гүзәл булыр”, дип яза. Әдип гаиләдәге ата-ана һәм бала мөнәсәбәтләре турында шундый шактый абстракт рәвештә генә фикер йөртеп калмый, ә балалар өчен киңәшләр дә бирә, ягъни гаилә әгъзаларының бер-берсе алдындагы бурычларын һәм хокукларын конкретлаштыра. Аның киңәшләре XIX йөзнең икенче яртысы – XX йөз башы яшь буынына гына түгел, хәзерге укучыларга да файдалы, һаман да актуаль.

Р.Фәхреддинов ата-аналарның үзләренә карата да таләпчән педагог була. Аның фикеренчә, ата-ананың төп бурычы – баланың өс-башын түгел, ә иң элек күңелен, холкын гүзәл итеп тәрбияләүдә. “Ихтимал ки, – дип яза ул, уразалар тотып, хаҗларга барып булдырылмаган саваплар, бала тәрбиясендә хасил булыр”

Гаиләдән кала, икенче тәрбия чыганагы – мәктәп-мәдрәсәләр. Халкыбызның аң-белем, мәгърифәт, мәктәп-мәдрәсә тарихы ерак гасырларга барып тоташа. Мәчет янына мәдрәсә салып куюны бабаларыбызның күркәм гадәте итеп бәяләргә кирәк. “Һәрбер кеше вә һәрбер кавем вә милләтнең бәхетле булуларына баш сәбәп – гыйлемдер. Ашлыклар өчен яңгыр никадәр кирәкле булса, адәм баласы өчен дә гыйлем – шул рәвештә кирәкледер”, – дип яза бу турыда Р.Фәхреддинов. Шул ук вакытта ул гыйлемле кешенең югары әхлаклы булу очрагында гына, милләт алгарышы өчен хезмәт куя ала торган шәхес булуын ассызыклый. Шунысы да игътибарга лаек: Р.Фәхреддиновның тәрбияви характердгаы китаплары җәмгыять тарафыннан бик җылы каршы алына. Һәрхәлдә, аерым хезмәтләренең унар-уникешәр мәртәбә басылуы шул хакта сөйли.

Нәтиҗә ясап, шуны ассызыкларга мөмкин: Р.Фәхреддинов төрле өлкәләргә караган фәнни хезмәтләр авторы, талантлы әдип, әмма аның иҗаты

һәм эшчәнлегенең йөзек кашы – әхлак гыйлеме, педагогик хезмәтләре. Алар XIX йөзнең икенче яртысында язылган булсалар да, хәзерге заман галимнәре, укытучылары тарафыннан да югары бәяләнә.

Хәзерге мәктәп шартларында Р.Фәхреддин иҗатын һәм хезмәтләрен тәрбия чарасы буларак куллану мөмкинлекләре шактый зур. Түбәндәге таблицада шуларның кайберләре мисал буларак бирелә.

Таблица

Белем алу һәм тәрбия процессында Р.Фәхреддин хезмәтләрен кулланунының кайбер юллары:

| Эш төре | Тәрбияләнүче сыйфатлар | Тәрбия процессы субъектлары, эшкә аңлатма |
|---|---|---|
| 9 нчы сыйныфта әдәбият дәресләрендә Р.Фәхреддинов тормышын, иҗатын өйрәнү | Гаделлек, белемгә омтылыш, изгелекнең тормышта җиңүенә ышаныч, тырышлык | Укытучы – юнәлеш бирүче, укучылар – бирелгән юнәлешкә буенча белемнәрне үзләштерүче. Нәтиҗәлелекне арттыру, рухи-әхлакый тәрбия сферасын актуальләштерү өчен, проектлар, паузалар ясап уку, фәлсәфи диалог кору алымнарын кулланырга мөмкин. |
| Ата-аналар җыелышында Р.Фәхреддиннең “Тәрбияле ана” исемле хезмәте буенча әңгәмә | Балаларда ялганчылык, әхлаксызлык, хәйләсезлек кебек тискәре сыйфатларның үсешен кисәтү | Ата-аналар һәм укытучы эшәнлектә турыдан-туры катнашса, ата-ана тәэсире нәтиҗәсендә укучы да әңгәмәнең тәрбияви тәэсиренең шифасын тояр, дип көтелә |
| “Сез – яраткан укытучым, сез – яраткан укучыларым” | мөгаллимнәргә ихтирам, гыйлемгә омтылыш, мәктәпне белем һәм тәрбия | Укытучы һәм укучы тәрбияви процессның тигез дәрәҗәдәге субъектлары буларак кабул ителә (шелтәләр белдерелми, билгеләр |

| | | |
|---|---|---|
| темасына сыйныф сәгате | учагы буларак кабул итү; үзеңнең хокук һәм бурычларыңны белү, мөгаллимнәрнең бурычлары турында мәгълүматлы булу | куелмый), дәрес әңгәмә рәвешендә алып барыла. |
| Р.Фәхреддин фикерләрен эпиграф рәвешендә куллану | Гаделлек, гыйлемгә омтылу, җинаятьчелектән саклану, ата-ана, мөгаллимнәргә ихтирам | Р.Фәхреддиннең канатлы гыйбарәләр дәрәҗәсендә кабул ителгән сүзләрен дәрес өчен эпиграф буларак, кабинет, мәктәп бизәлешендә кулланырга була. Бу очракта тәрбия субъектлары укучы, укытучы, мәктәп администрациясе, ата-ана булачак. |

Таблицадан күренгәнчә, Р.Фәхреддинов хезмәтләрен иҗади якын килеп куллану мөмкинлекләре бик зур. Кайбер очракларга кыскача аңлатма биреп китик.

Мәктәп программасына кертелгән тема буларак, әдип тормышын, иҗатын, хезмәтләрен өйрәнгәндә, әсәрнең идея эчтәлеге генә түгел, әхлакый эчтәлеген дә ачыкларга кирәк. Бу очракта югары сыйныф укучылары белән фәлсәфи, ягъни трансцендентлы диалог методына мөрәҗәгать итәргә була. Дәресне бу рәвешле оештырганда, мөгаллим һәм укучы диалогы яңа яссылыкка күтәрелә: бердәм фикергә килү максаты куелмыйча, иң мөһиме укучы шәхесенең кыйммәтләр сферасы актуальләшә, чөнки галимнәр язуынча,"трансцендентлы диалог тәрбия эшендә катнашучыларның хакыйкатьне эзләүгә, укытучы һәм укучы эшчәнлеге вакытында кыйммәтләр-идеалларның асылын һәм эчтәлеген аңлауга юнәлтелгән".

Эпиграф буларак Р.Фәхреддиннең кыйммәтле фикерләрен куллануны да бик отышлы. Эпиграфлар, беренче карашка гына, дәрес барышының,

кабинет бизәлешенең кечкенә өлешен тәшкил итәләр. Даими кулланганда, укучылар аларны әхлакый таяныч буларак, хакыйкать буларак кабул итә башлыйлар.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: Р.Фәхреддин – халкыбызның мәңге онытылмас классик язучысы, педагог-галим генә түгел,чын мәгънәсендә юл күрсәтүче йолдызыбыз, таянычыбыз да әле. Аның хезмәтенең тәрбияви потенциалын җитәрлек дәрәҗәдә кулланмау үсеп килүче буынны рухи-әхлакый яктан ярлыландырыр иде. Галим фикерләре укучыларга, укытучыларга, ата-аналарга да кызыклы, файдалы һәм төрле эш төрләрендә куллану мөмкинлекләренә ия булып торалар.

Р.Фәхреддиновның кешене иң элек камил әхлаклы, ягъни тышкы яктан да, эчке яктан да саф, чиста, гүзәл итеп күрергә телиләр, яшь буынны ата-ананы, мөгаллимнәрне ихтирам итәргә, туганнар һәм карендәшләр белән йомшак мөгамәләдә торырга, дусларны дөрес сайларга, тормышта күркәм максат күреп, шуңа туры барырга өндәүче мәгърифәтче, әдип, галим. Ул ике кодрәтле тәрбия чыганагы дип гаилә һәм мәктәп-мәдрәсәләрне атый. Р.Фәхреддин уйлавынча, мәктәп-мәдрәсәләрнең вазифалары – фәкать белем бирү генә түгел, моннан тыш, алар өстенә балаларның күңеленә Аллаһыны сөю, ул кушкан кануннардан читкә тайпылмыйча яшәү, яхшы гадәтләр, максатчанлык, гүзәл холык, тугрылык, гайрәтлелек, активлык кебек сыйфатларны тәрбияләү дә йөкләнә. Нәкъ менә шуңа күрә Р.Фәхреддинов кебек энциклопедик галимнәребезнең тәрбияви хезмәтләрен мәктәптә тәрбия процессында кулланырга кирәк.